ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан вазыйфага сайлана яисә билгеләп куела торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның таныклыклары турында

«Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан вазыйфага сайлана яисә билгеләп куела торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның таныклыклары турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Элек бирелгән таныклыклар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан вазыйфага сайлана яисә билгеләп куела торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затның вәкаләтләре чоры тәмамланганга кадәр гамәлдә булалар.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Секретарена йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2191-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2023 елның 19 октябрендәге
2191-VI ДС номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан вазыйфага сайлана яисә билгеләп куела торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның таныклыклары турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе урынбасарының, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторының, Татарстан Республикасы Конституция советы Рәисенең, Татарстан Республикасы Конституция советы әгъзасының, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан вазыйфага сайлана яисә билгеләп куела торган Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче башка затларның (алга таба шулай ук – Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат) таныклыгын рәсмиләштерү, бирү һәм кире кайтару тәртибен җайга сала.

Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына, җәмәгать судьяларына, отставкадагы җәмәгать судьяларына, үз вәкаләтләрен башкаруны туктаткан Татарстан Республикасы Конституциясе суды судьяларына кагылмый.

2. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның таныклыгы шәхесне таныклаучы һәм бу затка тиешле вәкаләтләр бирүне раслаучы документ була.

3. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затларга бердәй үрнәктәге таныклыклар бирелә.

4. Таныклыклар хуҗалары аларның сакланышы өчен персональ җаваплылыкка ия булалар.

## II. Таныклык үрнәге һәм тасвирламасы

5. Таныклык үрнәге:

а) таныклык тышлыгы:

| | |
|---|---|
| | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>ГЕРБ<br><br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН |

б) таныклыкның эчке ягы:

| | |
|---|---|
| **ТАНЫКЛЫК № ______**<br><br>**ФАМИЛИЯСЕ**<br>**ИСЕМЕ**<br>**АТАСЫНЫҢ ИСЕМЕ**<br>*(булганда)*<br><br>___________________________________<br>*(Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы исеме)*<br><br>**Татарстан Республикасы**<br>**Дәүләт Советы Рәисе __________________Ф.И.О.** | **УДОСТОВЕРЕНИЕ № ______**<br><br>ФОТО<br><br>**ФАМИЛИЯ**<br>**ИМЯ**<br>**ОТЧЕСТВО**<br>*(при наличии)*<br><br>___________________________________<br>*(наименование государственной должности Республики Татарстан)*<br><br>**Председатель Государственного**<br>**Совета Республики Татарстан ______________________Ф.И.О.** |
| *2023 – 2025 елларда гамәлдә* | *Действительно на 2023 – 2025 гг.* |

6. Таныклык тасвирламасы:

Таныклык тышлыгы ябык килеш 105 х 65 мм һәм ачык килеш 210 х 65 мм үлчәмдә куе кызыл төстәге ледериннан ясала.

Таныклык тышлыгының тышкы ягында уртада алтынсу төстәге фольгага 30 мм диаметрда Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте, аның өстендә баш хәрефләр белән 18 зурлыктагы шрифтта язылган «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ» язмасы, аның астында баш хәрефләр белән 18 зурлыктагы шрифтта язылган «РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН» язмасы басып төшерелә.

Таныклыкның эчке ягында (ачык килеш) алсу тангир челтәр җирлегендә текст язылган өстәмә бит бланкы ябыштырыла.

Өстәмә бит бланкының сул ягында татар телендә түбәндәге текст урнаштырыла:

өстә уртада – баш хәрефләр белән 11 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта – «ТАНЫКЛЫК» язмасы һәм таныклык номеры;

аста уртада – өч юлга баш хәрефләр белән 11 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта – Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

аста уртада – юл хәрефләре белән 9 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта – Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы исеме;

аста: ике юлга юл хәрефләре белән 9 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта сулда – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе» язмасы, уңда – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе инициаллары һәм фамилиясе;

аста – аеру сызыгы;

аста уртада – юл хәрефләре белән 8 зурлыктагы курсив шрифтта – таныклыкның гамәлдә булу срогы.

Өстәмә бит бланкының уң ягында рус телендә түбәндәге текст урнаштырыла:

өстә уртада – баш хәрефләр белән 11 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта – «УДОСТОВЕРЕНИЕ» язмасы һәм таныклык номеры;

өстәмә бит бланкы кырыеннан 5 мм аста сулда һәм аның вертикаль ягының уртасы буйлап – Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның 25 x 30 мм зурлыктагы төсле фоторәсеме;

уртада фоторәсемнән уңда:

өч юлга баш хәрефләр белән 11 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта – Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

аста – юл хәрефләре белән 9 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта – Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасы исеме;

аста: ике юлга юл хәрефләре белән 9 зурлыктагы яртылаш калын шрифтта сулда – «Председатель Государственного Совета Республики Татарстан» язмасы, уңда – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе инициаллары һәм фамилиясе;

аста – аеру сызыгы;

аста уртада – юл хәрефләре белән 8 зурлыктагы курсив шрифтта – таныклыкның гамәлдә булу срогы.

Таныклыкка өстәмә бит бланкына язмалар кара төстә Times New Roman шрифтында югары сыйфатлы итеп бастыра торган принтерда башкарылырга тиеш.

## III. Таныклыкларны рәсмиләштерү һәм бирү тәртибе

7. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына сайлау яисә билгеләп кую турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карары таныклыкны бирү өчен нигез була.

8. Таныклыкны рәсмиләштерүне тәэмин итү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан затны тиешле Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасына сайлау яисә билгеләп кую көненнән алып 30 календарь көн эчендә гамәлгә ашырыла.

9. Таныклыкларга номерлар бирү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

10. Таныклыкка Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе имза сала.

11. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе имзалары таныклыкка өстәмә бит бланкының ике ягында да Татарстан Республикасы Дәүләт Советының герблы мөһере белән таныклана. Таныклыкка өстәмә бит бланкының уң ягында мөһер фоторәсемнең аскы уң почмагын капларга тиеш.

12. Таныклыкка өстәмә бит бланкына ламинация ясала.

13. Таныклык Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның вәкаләтләре чорына бирелә.

14. Таныклык Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе яисә аның йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасарларының берсе тарафыннан бирелә. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат алынган таныклык өчен таныклыклар бирүне исәпкә алу журналында имза сала, аны алып баруны һәм саклауны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башкара.

15. Таныклыкны рәсмиләштергәндә аңа дөрес булмаган яисә төгәл булмаган язма кертелгән яисә башка хата җибәрелгән очракта, бозылган таныклык бланкы юкка чыгарылырга тиеш.

## IV. Таныклыкларны алмаштыру һәм кире кайтару тәртибе

16. Таныклык югалган, бозылган, табигый тузган, Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме үзгәргән очракта, әлеге затка яңа таныклык бирелә.

17. Яңа таныклыкны бирү Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе исеменә язылган гаризасы буенча башкарыла. Гаризада яңа таныклыкны бирү нигезләре күрсәтелә.

18. Яңа таныклыкны бирү гариза кергән көннән алып 30 календарь көн эчендә башкарыла. Таныклык югалганда Татарстан Республикасы дәүләт

вазыйфасын биләүче затка башка номерлы таныклык рәсмиләштерелә һәм бирелә. Таныклык бозылганда Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затка шул ук номерлы башка таныклык рәсмиләштерелә һәм бирелә.

19. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат биләгән вазыйфасыннан азат ителгән очракта, шул исәптән башка вазыйфага сайлануга яисә билгеләп куелуга бәйле рәвештә, шулай ук таныклыкны алмаштыруның барлык очракларында (югалтудан тыш) элек бирелгән таныклык Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенә кире кайтарылырга тиеш.

20. Таныклыкны кире кайтару турында таныклыклар бирүне исәпкә алу журналында тамга куела. Кире кайтарылган таныклык юкка чыгарылырга тиеш, бу хакта акт төзелә.

21. Вәкаләтләр чоры тәмамланганнан соң таныклык гамәлдә түгел дип санала һәм Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затта истәлеккә саклау өчен кала.

22. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче зат вафат булган очракта таныклык аның гаилә әгъзаларында истәлеккә саклау өчен калырга мөмкин.

## V. Йомгаклау нигезләмәләре

23. Таныклыклар бланклары (таныклыкларга өстәмә бит тышлыклары һәм бланклары) типография ысулы белән әзерләнә.

24. Таныклыклар бланклары белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Эшләр идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

25. Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затларның таныклыклары бланкларын исәпкә алу һәм саклау, шулай ук әлеге затларның таныклыкларын юкка чыгару Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан башкарыла.

26. Таныклыкларны рәсмиләштерүгә бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратын тотуга бүлеп бирелә торган акчалар исәбеннән һәм алар чикләрендә гамәлгә ашырыла.